# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге составына керүче Гоголиха авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

12 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 12 ноябрендә «2020 елда Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- Җирлек эчендәге юлларны караптоту;

- Торак пунктларда урамнарны яктырту.

- Контейнер мәйдан чыкларытөзү
ӘЙЕ ЮК
тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 26кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 17кеше .
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде::
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 17 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге составына керүче Гоголиха авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.
2.“2020 елда Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, кондезге бүлектә укучы блеге студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- Җирлек эчендәге юлларны караптоту;

- Торак пунктларда урамнарны яктырту.

- Контейнер мәйдан чыкларытөзү ӘЙЕ ЮК
тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Гоголиха авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Гоголиха авыл кибет бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга Гоголиха авылы, Мәктәп урамы 26 йорт

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зирекле авыл җирлеге башлыгы В.А.Данилова